ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.7, с. Шеланга, 422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Совет ур., 7 нче йорт, Шеланга авылы, 422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

23.10.2023 с. Соболевское № 3

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авылы җирлеге Соболевский авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 16 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авылы җирлеге Соболевский авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авылы җирлеге Соболевский авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтүгә ризалыгыгыз бармы:
- Соболевский авылында зират территориясен төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Соболевский авылы, Яр буе урамы адресы буенча , 50А йорт янындагы территориядә 11:00 сәгатьтә уздырырга.
4. Соболевский авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова